Туган тел дәресенең технологик картасы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районы ГБМБУ “54 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” I квалификацияле укытучысы
Шәвәлиева Лилия Фердинанд кызы

**Укыту предметы:** туган тел

**Сыйныф:** 1 (рус төркеме)

**Дәреснең темасы: “Ашамлыклар. Татар ризыклары”**

**Дәреснең максаты:** Ашамлыклар атамаларын искә төшерү; ризык атамаларын дөрес әйтүгә ирешү; яңа лексиканы кулланып, дөрес, тулы җөмләләр әйтә белү; “Кыстыбый” уенын уйный белү, уен кагыйдәләрен белү; дәреснең предмет нәтиҗәсен билгеләү.

**Дәреснең төп бурычлары**

**өйрәтү**: яңа сүзләр белән дөрес тәртиптә сүзтезмәләр төзергә өйрәтү;

**үстерү:** сүзтезмәләр белән дөрес, тулы җөмләләр төзи белүне оештыру;

**тәрбияви:** туган телгә мәхәббәт һәм аңа сакчыл караш тәрбияләү; ризыкның кадерен белергә өйрәтү.

**Дәреснең тибы:** яңа белем ачу.

**Көтелгән нәтиҗә**

**метапредмет нәтиҗәсе:** татар ризыклары турында белү.

**предмет нәтиҗәсе:** татар халык ашамлык атамаларын үзләштерү, аларны сөйләмдә актив куллану.

**шәхси нәтиҗә:** татар халык ашларына мәхәббәт тәрбияләү; истә калдыру күнекмәләрен ныгыту.
**Предметара бәйләнеш:** туган тел, әйләнә-тирә дөнья.
**Чыганаклар**
**төп:** Якупов Р.Н.“Сәлам!” 1нче сыйныф рустелле укучыларга татар телен өйрәнүне кызыклырак итү теләге белән язылган укыту әсбабы;
**өстәмә:** эш дәфтәре, интерактив такта, компьютер, аудиодиск, үзбәя бирү өчен карточкалар.
**Эшне оештыру төрләре**: фронталь, индивидуаль, парлап эшләү, төркемдә эшләү.
**Укучылар эшчәнлеге төрләре:** Аудиоматериал белән эш. “Кыстыбый” уенын уйнау, диалог һәм монолог сөйләү. Җыр җырлау.
**Төп эчтәлек (өйрәнелә торган лексика һәм сөйләм калыбы):** ашамлыклар, татар ризыклары, кыстыбый, коймак, чәкчәк, өчпочмак, бәлеш, баллы, ачы.

| Дәреснең дидактик этаплары | Дәрес этапларының төп максаты | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Дәрес этапларының нәтиҗәләре | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Шәхси нәтиҗә | Метапредмет нәтиҗәсе: УУГ формалаштыру | Предмет нәтиҗәсе |
| I.Оештыру | Уңай психологик халәт тудыру, дәрестәге эшчәнлеккә әзерләү | Дәрескә әзерлекне оештыру (исәнләшү; елмаеп, хәерле иртәләр (көн) теләү; хәлләрне сорашу). | Исәнләшү; елмаеп, хәерле иртәләр (көн) теләү;<br>хәлләрне сорашу;<br>эш урыннарының әзерлеген барлау | Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлаша белү сәләтләрен үстерү | Дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен булдыру | |
| II. Актуальләштерү | Ашамлыклар исемнәрен искә төшерү | -Укучылар, бу нәрсә?<br>-Карыйк әле, аның эчендә нәрсәләр бар икән?<br>1. Ул ак яки кара. Ул тәмле. Ул нәрсә?...<br>2. Ул ак. Ул тәмле түгел, ләкин кешегә кирәк. Ул нәрсә?...<br>3. Ул тәмле. Ул кайнар. Ул яшел, яки кызыл, яки кара. Ул нәрсә?...<br>4. Ул тәмле, ул баллы, ул сары, аның белән чәй эчәләр. Ул нәрсә?... | “Укытучы-укучы” диалогы:<br>-Бу кечкенә сандык.<br>1. -Ул ипи.<br>2. -Ул тоз.<br>3. -Ул чәй.<br>4. -Ул чәкчәк. | Диалог вакытында матур һәм дөрес итеп сөйләшә белү | Әңгәмәдәшең белән якын аралаша белү | Ашамлыклар исемнәрен дөрес әйтү |
| | Дәреснең темасын китереп чыгару | **Проблемалы сорау**<br>- Ә чәкчәк, ипи, йомырка... алар нәрсәләр?<br>-Әйе, укучылар, бу ашамлыклар, ризыклар. Ризык – это еда. | -Ашамлыклар (Продукты). | | | Ашамлыклар, ризык дип гомумиләштереп әйтә белү |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| III.Белем алуның төп мәсьәләләрен ачыклау | | -Укучылар, ә сез тагын нинди татар халык ризыкларын беләсез?<br>-Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшәбез?<br>-Дәреснең темасын ничек атыйбыз? | Укучылар белгәннәренә, кул күтәреп, җавап бирәләр.<br><br>-Ашамлыклар турында.<br>-“Ашамлыклар. Татар ризыклары” | Эшне үзара килешеп, әхлакый кагыйдәләрне үтәп оештыра белү | Теманы әйтә белү | Татар халык ризыкларын әйтә белү |
| | Дәреслектәге рәсем буенча сорауларга дөрес, тулы җавап бирүгә ирешү | **Дәреслектәге рәсем буенча эш.**<br>-Укучылар, дәреслекнең 103 битен ачабыз. 1нче рәсемне карыйбыз.<br>1. Бу кем?<br>2. Ә бу кем?<br>3. Алар кайда?<br>4. Алар кайда утыралар?<br>5. Алар нишлиләр?<br>6. Өстәлдә нәрсәләр бар?<br><br>7. Өчпочмак, кыстыбый, бәлеш, чәкчәк, коймак – алар нәрсәләр? | 1.–Бу әби.<br>2.–Бу малай.<br>3.–Алар өйдә.<br>4.–Өстәл янында.(За столом)<br>5.-Алар чәй эчәләр.<br>6.–Өчпочмак, кыстыбый, бәлеш, чәй, самовар....<br>7.-Татар ризыклары. | | Укытучыны тыңлап, сорауларга дөрес җавап бирә белү<br><br>Гомумиләште реп әйтә белү. | Бу кем?<br>Кайда?<br>Нишлиләр?<br>сорауларына дөрес җавап бирә белү.<br><br>Татар ризыклары дип әйтә белү. |
| | Ризык атамаларын дөрес әйтүгә ирешү | **Дәреслектәге 1нче рәсемгә аудиоязма тыңлатыла. (интерактив*)**<br>-Укучылыр, хәзер аудиоязманы игътибар белән тыңлыйбыз, дәреслектән сүзләрне карап барабыз.<br>-Укучылар, тагын бер тыңлыйбыз, кабатлап барабыз. | Укучылар аудиоязманы игътибар белән тыңлыйлар, дәреслектән карап баралар.<br><br>Аудиоязманы тагын бер тыңлап, сүзләрне кабатлап баралар. | Ишетеп аңлау күнекмәләрен булдыру. | Дәреслектән игътибар белән карап бару күнекмәләрен булдыру. | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **III.Белем алуның төп мәсьәләләрен ачыклау** | | **Рәсемле эш**<br>Укытучы укучыларга интерактив тактада яки карточкалар белән төрле ашамлыклар рәсемнәрен күрсәтә (ипи, сөт, ит, шикәр, тоз, күмәч, алма, йомырка, аш, чәй, ботка, балык) | Укучылар тиз темпта җавап бирәләр. | Реакция тизлеген формалаштыру | | Ипи, сөт, ит, шикәр, тоз, күмәч, алма, йомырка, аш, чәй, ботка, балык сүзләрен дөрес әйтү |
| | Яңа лексиканы кулланып, дөрес, тулы җөмләләр әйтә белү | **Сорау-җавап алымы**<br>Укытучы һәрбер укучыдан аның нәрсә яратуын сорый:<br>-Алия, син нәрсә яратасың?<br>-Ә өчпочмакка нәрсә кирәк? Бал кирәкме?<br>һ.б. турында | -Мин өчпочмак яратам.<br>-Өчпочмакка йомырка, сөт, май, он, тоз, шикәр кирәк.<br>-Юк, бал кирәк түгел. | | | Нәрсә яратканыңны тулы җөмлә белән әйтә белү.<br>Мәсәлән, өчпочмакны пешерү өчен нәрсәләр кирәклеген/ кирәк түгеллеген әйтә белү, |
| | Укучыларны ял иттерү<br><br>“Кыстыбый” уенын уйный белү, уен кагыйдәләрен белү | **Физкультминут** “Кыстыбый” уены<br>-Укучылыр, әйдәгез әле “Кыстыбый” уенын уйныйбыз!<br>*-Мин ашыйм,*<br>*-Син ашыйсың,*<br>*-Ул ашый.*<br>*-Менә нинди тәмле, сары, майлы, зур, кечкенә һ.б. кыстыбый!* | Укучылар уенның сүзләрен өйрәнәләр. Басып, бер-бер артлы такта янына тезеләләр. Һәр укучы басканда шигырьнең бер юлын әйтә. Укучылар сыйфатларны әйткәндә хәрәкәт-ишарәләр белән күрсәтергә тиеш. | Шәхес буларак эшчәнлек күнегүләр ясау | Төркемдә эшли белү. Уенны уйный белү. | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **IV.Ныгыту** | Яңа лексиканы сөйләмдә куллану, сорауга дөрес, тулы җавап бирә белергә өйрәтү | -Укучылар, бераз ял итеп, уйнап алдык.<br>**Дәреслектәге 2нче рәсемгә аудиоязма тыңлатыла.**<br>-Ә хәзер дәреслектәге икенче күнегүгә аудиоязманы тыңлыйбыз. Һәм тыңлаганнан соң *Кем нәрсә ярата дигән?* сорауга җавап бирәбез.<br>*Әти кара ипи ярата. Әби ак ипи ярата. Ул тәмле. Әни лимон ярата. Ул ачы. Мин кызыл алма яратам. Ул баллы. Песи балык ярата.*<br>-Әни нәрсә ярата?<br>-Лимон нинди?<br>-Әти нәрсә ярата?<br>-Артур нәрсә ярата?<br>-Ул нинди? ...һ.б. | Укучылыр дәреслектән игътибар белән тыңлыйлар, дәреслектән карап баралар.<br><br>Укучылар язманы игътибар белән тыңлаганнан соң, һәр гаилә кешесе турында сөйли алырга тиешләр.<br><br>-Әни лимон ярата.<br>-Лимон сары, ачы.<br>-Әти кара ипи ярата.<br>-Артур алма ярата.<br>-Ул кызыл, баллы, тәмле. | Ишетеп аңлау күнекмәләрен булдыру. | Куелган сорауга җөрес, тулы җавап бирә белү. | *Кем нәрсә ярата дигән?* сорауга җавап бирә белү. |
| | | | | Эшне үзара килешеп, әхлакый кагыйдәләрне үтәп оештыра белү. | | |
| | Язу күнекмәләрен формалаштыру | **Эш дәфтәредә эш.**<br>9нчы күнегү 66 бит (Җавабын яз) | Укучылар дәфтәрләрдә табышмакның җавапларын язалар.<br>Укытучы җаваплар язылган тактаны ача. Язма эш тикшерелә. Һәр дөрес җавапка “+” куела.(Укучылар дәфтәрләрен алышалар) | Зирәклек, тапкырлык сыйфатларын оештыру | Дөрес язу күнекмәләрен булдыру. Табышмаклар га җавап бирә белү. | Бирелгән сыйфатларны кулланып, исем белән гомумиләште реп әйтү. Мәсәлән, ул кызыл, |
| | | | | Классташының җавабын бәяли белү. | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **IV.Ныгыту** | | **Дәреслек белән эш.**<br>-Ә хәзер, укучылар, дәреслеккә кире кайтабыз. 3нче күнегүдәге рәсемнәргә карыйбыз.<br>Рәсемнәр буенча кызлар сораулар төзиләр, ә малайлар җавап бирәләр. | **Парларда эш.**<br>Кыз берәр малайга рәсем буенча сорау бирә, сайлап алынган малай җавап бирә.<br>1нче рәсем буенча эш<br>1нче кыз: - Бу кем?<br>1нче малай: -Бу әби.<br>2нче кыз: -Әби нәрсә ярата?<br>2нче малай: -Әби өчпочмак ярата.<br>3нче кыз: - Әби нәрсә ашый?<br>3нче малай: -Әби өчпочмак ашый. ...һ.б. | | | баллы,<br>тәмле...<br>җавабы: *алма* |
| | Җыр аша яңа лексиканы кертъ | **Җыр җырлау**<br>**-**Яхшы, укучылар. Әйдәгез әле, без сезнең белән җыр да җырлап алыйк әле. | **Укучылар җыр җырлыйлар.**<br>*Мин Тәмлетамак түгел,*<br>*Миңа күп кирәк түгел.*<br>*Сөт, ипи һәм йомырка -*<br>*Болары булсын сиңа!*<br>*Мин Тәмлетамак түгел,*<br>*Миңа күп кирәк түгел.*<br>*Аш, күмәч, балык, ботка -*<br>*Болары булсын сиңа!*<br>*Мин Тәмлетамак түгел,*<br>*Миңа күп кирәк түгел.*<br>*Шоколад һәм туңдырма -*<br>*Болары булсын миңа!* | Укучыларның күңелләрен, кәефләрен күтәрү | | |
| **V.Йомгаклау** | Дәреснең предмет нәтиҗәсен билгеләү | -Әфәрин, укучылар! Бик матур тырышып җырладыгыз!<br>-Укучылар, бу дәрестә сез нәрсәгә өйрәндегез, нәрсәләр белдегез? | -Ашамлыклар (ипи, сөт...һ.б.) турында сөйләштек.<br>-Татар ризыкларын белдек.<br>-Нәрсә яратканны әйтергә өйрәндек.<br>-Нәрсә ашаганны әйтергә өйрәндек.<br>-“Кыстыбый” уенын | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **VI.Рефлексия. Үзбәя һәм бәя куюу** | Эшкә үзбәя бирергә өйрәтү | -Укучылар, сезнең парталарда түгәрәкләр.<br>-Түгәрәкләр нинди төстә?<br>*Укытучы төсләрнең нәрсә аңлатканын искә төшереп китә.*<br>-Әгәр дәрес сезгә ошаса, теманы аңладыгыз, сорауларга дөрес җавап бирә алдыгыз икән, сез кызыл түгәрәк күтәрәсез.<br>-Әгәр дәрестә теманы аңладыгыз, сорауларга җавап бирдегез, ләкин хаталар ясадыгыз, сез яшел түгәрәкне күтәрәсез.<br>-Әгәр дәрестә бернәрсәдә аңламадыгыз икән, сораулар булса, сез сары түгәрәкне күтәрәсез.<br>*Укучылар түгәрәкләрен күтәргәннән соң, һәрбер укучыга дәрестә ничек эшләгәннәре турында анализ ясап, дәресне тәмамлый.*<br>-Укучылар, сез дәрестә актив катнаштыгыз, барыгыз да сорауларга җөрес җавап бирергә | -Кызыл, яшел, сары төстә.<br><br>Укучылар түгәрәкләрен күтәрәләр. | Үз уңышларыңн ың/уңышсызл ыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртә белү | Үз эшчәнлегеңне контрольгә алу | |
| | | тырыштыгыз, дәреслек белән дә, дәфтәрдә дә эшләдегез, уенны да, җырны да матур итеп башкардыгыз. | | | | |